**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**УРТА БАЛТАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАРЫ**

2020 ел, 6 июль № 184

**Урта Балтай авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законы, Татарстан Республикасы Муниципаль хезмәт турында 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы кодексы, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының «Урта Балтай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Урта Балтай авыл җирлеге Советы **карар итте:**

1.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Урта Балтай авыл җирлеге Советының «Урта Балтай авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмә хакында» 2016 елның 12 февралендәге 15 номерлы карарының «Урта Балтай авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмә»нең 1 нче кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 8.3 пунктның 6 пунктчасында «мәҗбүри пенсия иминиятенең иминият таныклыгы» сүзләрен «индивидуаль (персонификацияләнгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслаучы документ»сүзләренә алмаштырырга.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Урта Балтай авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

**Урта Балтай авыл**
**җирлеге Башлыгы урынбасары** **Ш.К. Гарифуллин**